# КАРАР

**25 ноябрь, 2022 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Тәмәй авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 25 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

« 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча укучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан), 80 яшькә җиткән һәм аннан да өлкәнрәк кешеләрдән, 4 баласы һәм аннан да күбрәк балалары булган куп балалы гаилэлэрдэн,18 яшькә кадәрге баланы тәрбияләүче ялгыз аналардан, 80 һәм аннан өлкәнрәкләрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан , җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалардан тыш, 2023 елда һәр бэлигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә илешәсезме?:

- Тәмәй авылындагы урам - юл челтәрен төзекләндерү,ремонтлау , проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.
- тирән насослар сатып алу һәм урнаштыру , Тәмәй авылын су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау , проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;"

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 52 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 32 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 32 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Мәмәшир авыл җирлегенең Тәмәй авылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны:

1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча укучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан), 80 яшькә җиткән һәм аннан да өлкәнрәк

кешеләрдән, 4 баласы һәм аннан да күбрәк балалары булган куп балалы гаилэлэрдэн,18 яшькә кадәрге баланы тәрбияләүче ялгыз аналардан, 80 һәм аннан өлкәнрәкләрдән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан , җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалардан тыш, 2023 елда һәр бэлигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә илешәсезме?:
- Тәмәй авылындагы урам - юл челтәрен төзекләндерү,ремонтлау , проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.
- тирән насослар сатып алу һәм урнаштыру , Тәмәй авылын су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау , проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;"

« «РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Мәмәшир авыл җирлеге башлыгы И.Г.Әхмәтҗанов